| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАЛОМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 апрель Кече Мәми авылы №7

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Кече Мәми авыл җирлеге Башкарма комитетының**
**баш хисапчысы (муниципаль хезмәткәрләр**
**вазифаларына кертелгән вазыйфалардан тыш)**
**хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында.**

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге башкарма комитеты баш хисапчысының хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2.Әлеге карар нигезендә билгеләнә торган хезмәткәрнең хезмәт хакы күләме хезмәткәрнең вазыйфаи бурычлары күләмен һәм шул ук квалификация эшләрен башкарганда 2019 елның 31 мартына түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

3.Әлеге карар 2019 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Кече Мәми авыл җирлеге башлыгы** **Е.Н. Алексеева**

Кече Мәми авыл җирлеге
Башкарма комитетның
2019 ел, 29 апрель, 7 нче номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Нигезләмә**
**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге башкарма комитеты баш хисапчысының хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында**

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Башкарма комитетының баш хисапчысына хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы әлеге нигезләмә хисапчылар эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлый һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәрен һәм аларны бирү шартларын билгели.
2.Хисапчыларның хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, матди ярдәм һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр тәшкил итә.
3. Хисапчыларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифа | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары вазыйфасы халык саны белән |
|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше |
| Баш хисапчы | 15 700 сум |
| Хисапчы | - |

Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары штат расписаниесенә хисапчы вазыйфасын кертү шарты булып муниципаль берәмлекнең халык саны 3,5 меңнән артык кеше тора.
3. Хисапчыларга билгеләнә:
1) түбәндәге күләмнәрдә тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә:

| Эш стажы булганда | Айлык өстәмә, процент |
|---|---|
| 1елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15елга кадәр | 10 |
| 15елдан артык | 15 |

2) вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;
3) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү күләме елына вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә;

Әгәр хисапчыларга календарь ел дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган акча түләнелә һәм декабрьдә, эштән азат ителгән очракта, аңа пропорциональ рәвештә түләнә.

Беренче елда еллык түләүле отпуск биргәндә хисапчыларга бер тапкыр түләнә торган түләү календарь елында башкарылган вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы елның 31 декабренә эшкә кергән көннән исәпләнә.

4) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм күрсәтү;
5) ай һәм квартал эш нәтиҗәләре буенча премия.
4. Хисапчыларның еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формуласы буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} \mathrm{P} * (1 + t);$$

кайда:
FOT – хисапчыларның еллык хезмәт хакы фонды ;
$O_d$- хисапчыларга хезмәт окладларын түләү өчен акча суммасы;
$0{,}3 * O_d$ - тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, еллык түләүле отпуск, матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр түләнә торган түләү өчен акча суммасы;
Р – хисапчыларның еллык премиаль фонды (әлеге Нигезләмәнең 3 пунктындагы 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә торган));
n-хисапчыларның штат саны;
k-12 ай;
$t$ -хезмәт өчен түләү буенча түләүләр исәпләү.